ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

27.12.2023 п.г.т.Алексеевское № 635

**2024 елга Алексеевск муниципаль районында халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифлар турында**

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «2024-2028 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индекслары турында» 15.12.2023 ел, № 867 Татарстан Республикасы Рәисе Указы нигезендә,

**карар бирәм**:

1. 2024 елга Алексеевск муниципаль районында халыкка күрсәтелә торган торак хезмәтләренә тарифларларны расларга:

- дәүләт яки муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынын тоткан өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны тоткан өчен түләү күләме (Кушымта № 1).

- дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак бинасыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү) (Кушымта № 2).

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://alekseevskiy.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
27.12.2023 № 635 карарына
1 нче кушымта

**Дәүләт яки муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре һәм торак урыннарын наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урынын тоткан өчен һәм күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлап алу турында карар кабул итмәгән торак урыннары милекчеләре өчен торак урынны тоткан өчен түләү күләме**

| № | Хезмәт исеме | Түләү алына торганның үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тарифлар (сумнарда) | |
|---|---|---|---|---|
| | | | 01.01. - 30.06. | 01.07. - 31.12. |
| 1 | Торак фонды белән идарә итү | торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. айга | 3,40 | 3,71 |
| 2 | Йорт яны территориясен санитар карап тоту һәм санитар чистарту | торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. айга | 2,15 | 2,35 |
| 3 | Торак биналарны агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. айга | 3,67 | 4,0 |
| 4 | Йорт эчендәге инженер җиһазларына техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау:<br>- йорт эчендәге санитар-техник челтәрләрен<br>- җылыту челтәрләрен | торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. айга | 1,85<br><br>- | 2,02<br><br>- |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Торак йортларда йорт эчендәге газ челтәрләренә һәм йорт эчендәге газ җиһазларына техник хезмәт күрсәтү | торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. айга | 0,43 | 0,47 |
| 6 | Электр челтәрләренә техник хезмәт күрсәтү | торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. айга | 1,09 | 1,19 |
| 7 | Вентиляция каналларына һәм төтен юлларына техник хезмәт күрсәтү | торак бинаның гомуми мәйданының кв. м. айга | - | 0,35 |

**Башкарма комитетның**
**эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Татарстан Республикасы
Алексеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
27.12.2023 № 635 карарына
2 нче кушымта

**Дәүләт яисә муниципаль торак фондының торак бинасыннан файдаланган өчен (наем өчен түләү)түләү күләме**

| Хезмәт исеме | Хезмәтнең үлчәү берәмлеге | Хезмәт күрсәтүнең үлчәү берәмлеге өчен тарифлар (сумнарда) | |
|---|---|---|---|
| | | 01.01. - 30.06. | 01.07. - 31.12. |
| Наем | торак бинаның гомуми мәйданының 1 кв. м. айга | 7,57 | 7,57 |

**Башкарма комитетының эшләр идарәчесе** **Г.Ә. Йосыпова**